Республика Татарстан
Старо-Имянское сельское
поселение Сармановского
муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль
районы Иске Имән
авыл җирлеге

КАРАР
21.06.2018

КАРАР
№ 86

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең сайланулы вазыйфаи затына хезмәт өчен түләү нигезләмәсенә үзгәрешләр кертү турында

«Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, контроль-хисап органнары рәисләренә, Татарстан Республикасы муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары нигезендә Иске Имән авыл җирлеге Советы КАРАР итте:

1. Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге Советының 27.04.2018 ел, № 81 карары белән расланган " Иске Имән авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең сайланулы вазыйфаи затына хезмәт өчен түләү турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 1 кушымтаның 3 пунктындагы 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Иске Имән авыл җирлегенең сайланулы вазыйфаи затына айлык акчалата түләү өлешендә хезмәт өчен түләү чыгымнары елына 4,65 айлык акчалата түләү тәшкил итә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлеге
Советы рәисе

Р.Ә.Исламова